| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАДЫБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАДЫБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.09.2019 Кадыбаш авылы № 9

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 8 декабрендәге 14 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турындагы» карары белән расланган административ регламентларның үз көчен югалтуын тану хакында

Авыл җирлеге норматив-хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге башкарма комитеты Карар бирә:

1. Түбәндәге административ регламентларны үз көчен югалткан дип танырга:

1.1. Торак бинаны үзгәртеп коруны һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны килешү (килешмәү) турында Карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

1.2. Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

1.3. Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә административ регламенты;

1.4. Агач һәм куаклар кисүгә, кронировкалауга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент;

1.5. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент;

1.6. Документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең тугрылыгын таныклау(дөреслеген раслау) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент;

1.7.Васыятьнамә яки ышанычнамә таныклыгы нотариаль гамәлләре кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты;

1.8. Авиация эшләрен башкаруга, парашют сикерүләренә, җирлек территориясеннән бәйләнгән аэростатларны күтәрүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

2. Әлеге карарны Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Кадыбаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә http://agryz.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.Г.Рамазанов

АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Совет Кадыбашского сельского поселения
Кадыбаш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002572
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ